Минзәлә муниципаль районының
Югары Тәкермән авыл җирлеге Башкарма комитеты
Карары

от «27» март 2020 ел. №10

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының
Югары Тәкермән авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасының “Җирле референдум турында”гы 23-ЗРТ номерлы Законы, Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Югары Тәкермән авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Югары Тәкермән авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.
2. Әлеге карар рәсми төстә басылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә йөклим.

Авыл җирлеге башлыгы Шәрипова А.Ә..

Совет ВЕРХНЕ-ТАКЕРМЕНСКОГО сельского поселения ОГРН 1021605552704 ИНН 1628002770

ТР Минзәлә муниципаль районы
Югары Тәкермән авыл җирлеге
Башкарма комитеты
Карарына 1 нче кушымта
дата 27.03 2020 ел. N 10

ТР Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарга үзара салым акчаларын түләтү Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм инвалидлардан, шулай ук 1 төркем инвалидлардан тыш, 18 яше тулган, Минзәлә муниципаль районының Югары Тэкермэн шәһәре территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан, аларныц җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуына һәм тавыш бирүдә белдерелгән мөнәсәбәтенә бәйсез рәвештә, 31 мартка кадәр срокта башкарыла.

3. Аерым категорияле гражданнар өчен:
- Бөек Ватан сугышы ветераннары;
- Бөек Ватан сугышында катнашучыларныц тол хатыннары,
- 1 һәм 2 төркем инвалидлар;
- биш һәм аннан күбрәк балалы күпбалалы әниләр.

Җитди сәбәпләр булганда, аларга түбәндәгеләр керергә мөмкин:
а) авыру;
б) озакка сузылган командировка;
өч айдан артмаган срокка гариза нигезендә гражданнарга түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр язуы (уведомление) бланкы Җирлекнең мәгълүмати стендында, Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлегенең menselinsk.tatarstan.ru рәсми сайтында бастыру, шулай ук имза куйдырып тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән гражданнарга җиткерелә.

5. Хәбәр язуында (уведомление) гражданнарныц үзара салым акчаларын кертүгә түләү реквизитлары, тулысынча яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү күләме, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш (Кушымта).

6. Гражданнарның үзара салымнан кергән акчалата чаралары Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлегенең лицевой счетына керә.

7. Гражданнардан түләү алу почта (хисап оешмалары) переводларын башкаруга физик затларның йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясауга хокукы булган оешмалар, Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы, https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша акчаларны күчерү юлы белән башкарыла.

8. Касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслаучы булып тора.

9. Билгеләнгән срокта гражданнардан алынмаган үзара салым акчалары законда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

ХӘБӘР ЯЗУЫ (УВЕДОМЛЕНИЕ) N ______________ Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү кертү турында

түләүченең Ф.Ис.Ат.ис. ________________________________________________________

Адресы: ______________________________________________________________________

______________________________________________________________ нигезендә

Сезгә ____________ срокка кадәр _______________________ чараларны гамәлгә

__________________________________________ ашыруга бер тапкыр түләү кертергә кирәк.

суммада _______________ сум, түбәндәге реквизитлар буенча:___________________

Түләү алучы банкның БИК ________________________________________________________
Сч. N ___________________________________________________________________________
Кабул итүче Сч. N ______________________________________________________________
КПП ____________________________________________________________________________
КБК _______________ ОКАТО ___________________
Түләү билгеләнеше ______________________________________________________________
Җитәкче _________________ ______________________________________
М.У. (имза) (тулысынча имза)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәр язуы (Уведомление) N _________________
Үзара салым буенча бюджетка бер тапкыр түләү кертү турында _______________________
_________________________________________________________________________
(муниципаль берәмлек атамасы)
суммада ________________ сум.

түләүченең Ф.Ис.Ат.ис. __________________________________________________________
Адресы: _________________________________________________________________________
Алдым "___" _______________ 20___ ел. _____________________________________

______________________
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Хәбәр язуы төпсәсе (корешок) тутырыла һәм хәбәр язуы түләүченең шәхсән үзенә тапшырылган очракта, Башкарма комитетта кала.